| ГЛАВА<br>Кадряковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кадрәк авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|

29.10.2025 Кадрәк авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы « Кадрәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Кадрәк
торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган

акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кадрәк авылының Ленин, Нарат, Басу, Елга аръягы, Яшьләр урамнарына вак ташлар сатып алу һәм салу);

- торак пункты чикләрендә җәяүлеләр күперләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына кермәгән җәяүлеләр өчен җир өсте юлларын ремонтлау (Кадрәк авылы авыл җирлеге чикләрендәге күперләрне ремонтлау һәм карап тоту);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү);

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү һәм торак пунктның аларга якын территорияләрен төзекләндерү (кышын Ленин, Басу, Яшьләр, Елга аръягы, Нарат урамнары буенча юлларны чистарту), тракторны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, мәдәният йорты, ФАП, административ бина коймаларын ремонтлау, төзекләндерү буенча башка чыгымнар;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Кадрәк торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. 3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадрәк авылы, Ленин урамы, 55нче йорт, авыл мәдәният сарае адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә,

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм  “Интернет” мәгъләмат-телекоммуникация челтәренең  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов

Совет Кадряковского сельского поселения
Кадрәк авыл җирлеге Советы